КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 19 март г.Казань № 162

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 март, 133 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибен раслау хакында» 2021 ел, 15 март, 133 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 гыйнвар, 69 нчы; 2022 ел, 30 июль, 736 нчы, 2022 ел, 21 ноябрь, 1245 нче, 2023 ел, 4 февраль, 98 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында торак төзелеше

үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә социаль ипотека системасында торакка хокукын гамәлгә ашыручы гаиләләргә бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда дәүләт ярдәме күрсәтү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында махсуслаштырылган оешма булып торучы коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалкан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3 пунктта:

икенче абзацка «(булганда)» сүзен өстәргә;

өченче абзацта «мөһере» сүзеннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацка «(булганда)» сүзен өстәргә;

уникенче абзацка «(булганда)» сүзен өстәргә;

унөченче абзацка «мөһере» сүзеннән соң «(булганда)» сүзен өстәргә.

2. Бу карар (бу карарның 2024 елның 1 июненнән үз көченә керә торган 1 пунктындагы өченче - сигезенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин